ГЛАВА МАКУЛОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
МАКЫЛ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

22.10.2018 с. Русское Макулово 06

Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге Сеитово авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56нчы статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35нче статьясына, Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге Уставының 24нче статьясына туры китереп,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2018 елның 6 ноябренә Югары Ослан районының Макыл авыл җирлегенең Сеитово авылы җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

“2019 елда Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлегенең Сеитово авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү белән килешәсезме:

- Сеитово авылында җирле әһәмияттәге юлларны ремонтлау

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Халык җыенын Сеитово авылы, Центральная урамы, 6 нчы йорт адресы буенча урнашкан кибет бинасында үткәрергә.

Макыл авыл җирлегенең башкарма комитеты гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

5. Әлеге карарны «Волжская новь» район газетасында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырырга, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

6. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

ТР Югары Ослан муниципаль районы
Макыл авыл җирлеге башлыгы А.И. Матвеева